**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кызыл Яр торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 17 нояберендә 9:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
«2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кызыл Яр торак пункты территориясендә көндезге формада белем алучы студентлардан,Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан,ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Иске Кызыл Яр авылында зират коймаларын яңарту.

2.Иске Кызыл Яравылында су башнясы өчен тирәнлек насослары сатып алу.

3. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу.

4.Урамнарны кардан чистарту, дизель ягулыгы алу һәм тракторчыга килешү буенча хезмәт хакы түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 21 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 13 кеше, бу 62 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 13 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кызыл Яр торак пункты территориясендә, көндезге формада белем алучы студентлардан,Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан, ирекрәреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1.Иске Кызыл Яр авылында зират коймаларын яңарту.

2.Иске Кызыл Яравылында су башнясы өчен тирәнлек насослары сатып алу.

3. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу.

4.Урамнарны кардан чистарту, дизель ягулыгы алу һәм тракторчыга килешү буенча хезмәт хакы түләү.

4.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М.ШАКИРОВ